| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СОСНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОСНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«19» декабрь 2025 ел №14

**Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сосна авыл җирлеге башлыгының, Сосна авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 25.12.2018 елның 94 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (28.03.2023 №63, 17.07.2024 №101, 31.10.2024 №105, 14.05.2025 №127нче номерлы үзгәрешләре белән)**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 елның №182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025 елның №994 нче номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 28.04.2018 елның №127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 17.12.2025 елның № 26 нчы номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 25.12.2018 елның №94 нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге советы карарына (28.03.2023 №63, 17.07.2024 №101, 31.10.2024

№105, 14.05.2025 №127 нче номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «21 091» санын «23 201» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар имза куйган көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов